ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы,
422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

19.11.2022 № 03

На №____________ от______________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?- Татар Макылы авылы зиратының керү төркеме каршында тукталыш мәйданын һәм аңа керү юлын бетонлау, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 19 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 115 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 7 кеше кертелгән. Кворум юк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында гражданнар җыенын узмаган дип танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге башлыгының урынбасарына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: П.Е.Карпухин